| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2020 Зур Тигәнәле авылы № 4

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карарын үтәү максатында

**карар кылам:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарына кушымтаны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга, Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 йорт адресы буенча Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында һәм Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 йорт адресы буенча “Әшнәк” кибете бинасында махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **С.Ж.Әхмәтҗанов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Зур Тигәнәле авыл җирлеге
башкарма комитетының
2020 елның 10 февраленнән 4
номерлы карарына кушымта

Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2020 елның 1 февраленнән

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3431,09 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1101,97 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1591,80 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе
2020 елның 1 февраленнән

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәрхүмне киендерү (кәфенләү) | 1160,61 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2270,48 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1101,97 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1591,80 |
| Барлыгы | 6124,86 |